

Хезмәт кешеләре, эшләрендә танылу тапкан кешеләр турында һәрвакыт язасы килеп тора. Алар житди һәм ижади хезмәтләре нәтижәсендә кvп нәрсәгә ирешәләр. Бу кешеләрне, барыннан да элек, максатчанлык, намуслылык һәм vз эшенне ярату берләштерә.
Ватаныбызнын муллыгы һәрвакыт хезмәт соючән кешеләргә бәйле. Ә бит нәкъ аларнын тырышлыгы белән бvгенге кондә дә илебез чәчәк ата. Һәм менә без «Ромодановосахар» жәмгыятчелегендә тырышып I, II сатурация  һәм  контроль, сокларны  фильтрацияләv производство участогы операторы (оператор производственного участка фильтрации соков I, II сатурации и контрольной фильтрации) булып хезмәт итә торган Альбина Айса кызы Шарибжанова турында сойлибез. Ул шикәр ясарга булыша.     Альбина  Айса  кызы заводка  2006 елда килә һәм чогендер жомын аеру буенча машинист булып эшли башлый. 2010 елда аны сиропларнын диск фильтрлаштыру буенча I стадия фильтрация һәм сульфитация участогы операторы вазыйфасына кvчергәннәр, ә 2014 елдан ул I, II сатурация һәм контроль, сокларны фильтрацияләv производство участогы операторы булып нәтижәле хезмәт итә. Бу еллар эчендә безнен героиня vзен бары тик унай яктан гына кvрсәткән һәм бvген югары квалификацияле белгеч булып тора. Ул контрольдә тоткан сокларны фильтрацияләv про-цессы һәр вакуум-аппараттан шикәр чыгунын артуына китерә. Эшкә оста якын килv ана фильтрация станциясендә максималь кvрсәткечләргә ирешергә момкинлек бирә. Анын хезмәт соючәнлеге һәм жаваплылыгы аркасында, эшләгән сменасы яхшы нәтижәләргә ирешә. Тупланган тәжрибәсе һәм белемнәре белән ул заводка яна гына эшкә килгән яшь эшчеләр белән уртаклаша.
Кvпьеллык тырыш хезмәте очен Альбина Айсеевна Шарибжанова Россия шикәр житештерvчеләр берлегенен Мактау грамотасына, Мордовия Республикасы Главасынын Рәхмәт хатларына, Мордовия Республикасы Авыл хужалыгы һәм азык-толек министрлы-гынын грамоталарына лаек. Киләчәктә дә илебезнен агросәнәгать комплексында яна хезмәт казанышлары булырга насыйп итсен.
Альбина Айса кызынын гаиләсе дә бик матур; тормыш иптәше белән бергәләп Азат, Азамат улларын һәм Алина кызларын тәрбиялиләр. Ул эштә дә, гаиләдә дә унган.

Наилә НАСЫРОВА